**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5741**
**02.11.2020**

Башкарма комитетның 2019 елның 28 августындагы 4427 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 28 августындагы 4427 номерлы карары белән расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) аерым затның ул ия булган (булучы) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

2) күчемсез милек объектына хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

3) күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;;

4) үлемне дәүләт теркәве турында мәгълүмат;

5) торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган мәгълүмат»;

2) 3.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Район хакимияте белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кирәкле мәгълүмат бирү турында запрос җибәрә.»;

3) 3.6.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов